**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

21.03.2022 204-п

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ
«ЯН» социаль объектлар идарәсенең
шифаханә-профилакторие территориясендә
33, 33р номерлы су алу скважиналарының
санитар саклык зоналарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, «Су белән тәэмин итү чыганакларының һәм эчә торган су үткәргечләренең санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары, «Җир асты суларын пычранудан саклауга карата гигиена таләпләре. СП 2.1.5.1059-01» санитария кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы нигезендә, 2011 елның 15 сентябрендәге җир асты байлыкларыннан файдалануга ТАТ 01651 ВЭ лицензиясен, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләренә һәм нормативларына туры килү турында 2019 елның 19 декабрендәге №16.07.01.000.Т.000016.12.19 санитар-эпидемиология бәяләмәсен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ЯН» социаль объектлар идарәсенең шифаханә-профилакторие территориясендә 33, 33р номерлы су алу скважиналарының санитар саклык зоналары проекты нигезендә

боерык бирәм:

1. Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибы тарафыннан 2002 елның 26 февралендә расланган «Су белән тәэмин итү һәм эчә торган су үткәргечләре чыганакларының санитар саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә әлеге боерыкның 1 нче кушымтасындагы чикләрдә, әлеге боерыкның 2 нче кушымтасындагы

территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы белән В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ЯН» социаль объектлар идарәсенең шифаханә-профилактории территориясендә 33, 33р номерлы су алу скважиналарының санитар саклык зоналарын билгеләргә.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ЯН» социаль объектлар идарәсенә;

- «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФБУ филиалына, – санитар саклык зонасын билгеләү турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына.

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләр буенча чаралар уздыруны тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ЯН» социаль объектлар идарәсенең шифаханә-профилактории территориясендә 33, 33р номерлы су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләре турында, су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану кагыйдәләре һәм режимы хакында халыкка хәбәр итүне оештыру турында;

- территорияләрне үстерүнең территориаль комплекс схемаларын, функциональ зоналаштыру схемаларын, җир корылышы схемаларын, районнарны планлаштыру проектларын һәм генераль планнарны эшләгәндә санитар саклык зоналарын билгеләү турындагы карарны исәпкә алуны оештыру турында.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2022 елның 21
мартындагы 204-п номерлы
боерыгына 1 нче кушымта

**В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ЯН» социаль объектлар идарәсенең шифаханә-профилакторие территориясендә 33, 33р номерлы су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләре**

Эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында җир асты суларын чыгару өчен файдаланыла торган гамәлдәге скважиналар участогы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәреннән 5,3 км төньяктарак, Поташ Аланы торак пунктының көньяк-көнчыгыш кырыенда В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ЯН» социаль объектлар идарәсенең шифаханә-профилакторие территориясендә урнашкан.

Су алу җайланмасы файдаланыла торган ике скважинадан тора, скважиналар арасы – бер-берсеннән 13 м.

Скважиналарның географик координатлары:

№33 - 54°58'0,226" төн.киң., 52°21'54,720" көнч. оз.;

№33р - 54°57'59,845" төн.киң., 52°21'54,357" көнч. оз.

Санитар саклык зонасының беренче поясы астында урнашкан җир кишәрлегенең кадастр номеры: 16:07:010004:0250.

Санитар саклык зоналары өч пояс составына оештырыла: беренче пояс (катгый режимлы) су алу корылмасы урнашкан территорияне, барлык сууткәргеч корылмаларының һәм су үткәрү каналы мәйданчыкларын үз эченә ала. Икенче һәм өченче пояслар (чикләүләр пояслары) су белән тәэмин итү чыганагы пычрануын кисәтү өчен билгеләнгән территорияне үз эченә ала.

Санитар саклык зонасының I поясы.

33 номерлы скважина өчен санитар саклык зонасының беренче пояс чиге төньяк-көнбатыштан – 12 м, төньяк-көнчыгыштан – 17 м, көньяк-көнчыгыштан – 7 м, көньяк-көнбатыштан – 12 м; 33р номерлы скважина өчен беренче пояс чиге төньяк-көнбатыш юнәлештән – 4 м, төньяк-көнчыгыштан – 4 м, көньяк-көнчыгыштан – 10 м һәм көньяк-көнбатыштан 25 м аралыгында билгеләнә.

Санитар саклык зонасының II поясы

Санитар саклык зонасының икенче пояс чиге түбәндәгечә билгеләнә: агым буенча аска таба – 85 м, агым буенча өскә таба – 102 м, киңлеге – 196 м;

Санитар саклык зонасының III поясы

Санитар саклык зонасының өченче пояс чиге түбәндәгечә билгеләнә: агым буенча аска таба – 170 м, агым буенча өскә таба – 1500 м, киңлеге – 990 м.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 21 мартындагы 204-п номерлы боерыгына 2 нче кушымта

**В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ «ЯН» социаль объектлар идарәсенең шифаханә-профилакторие территориясендә 33, 33р номерлы су алу скважиналарының санитар саклык зоналары чикләрендә территорияләрдән хуҗалык өчен файдалану режимы**

1. Санитар саклык зонасының беренче поясы буенча чаралар

1.1. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясе өслек агымын аннан читкә агызып җибәрү өчен планлаштырылган, яшелләндерелгән, коймалап алынган һәм сак белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Корылмаларга бара торган юллар каты өслекле булырга тиеш.

1.2. Санитар саклык зонасындагы беренче пояс территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми: биек кәүсәле агачлар утырту, төзелешнең су үктәрү корылмаларын эксплуатацияләү, үзгәртеп кору һәм киңәйтүгә турыдан-туры кагылышы булмаган барлык төрләре, шул исәптән төрле билгеләнештәге торбаүткәргечләр салу, торак һәм хуҗалык-көнкүреш биналары урнаштыру, кешеләрне яшәтү, агулы химикатлар һәм ашламалар куллану.

1.3. Санитар-саклык зонасының беренче поясы территориясендәге биналар ташландык суларны көнкүреш яки эшчәнлек канализациясенең иң якын системасына яки санитар-саклык зонасындагы беренче пояcтан читтә икенче пояс территориясендәге санитар режимны исәпкә алып урнаштырылган җирле чистарту корылмалары станцияләренә агыза торган канализация белән җиһазландырылырга тиеш.

Искәрмәле очракларда, канализация булмаса, санитар саклык зонасының беренче поясы территориясе пычрануга юл куймый торган урыннарда урнашкан, нәҗесләрне һәм көнкүреш калдыкларын кабул итү өчен, аларны чыгарганда су үткәрми торган корылмалар төзелергә тиеш.

1.4. Санитар саклык зонасының беренче поясында урнашкан су үткәрү корылмалары скважина очлыклары һәм скважина авызлары, резервуарларның люклары һәм агызу торбалары һәм насосларга су тутыру җайланмалары пычрану мөмкинлеген калдырмауны исәпкә алып җиһазландырылырга тиеш.

1.5. Су алу корылмаларының барысы да су алу корылмасын проектлаганда һәм санитар саклык зонасы чикләрен нигезләгәндә каралган проект җитештерүчәнлегендәге су алу корылмасын эксплуатацияләгәндә фактик дебитның туры килүенә системалы тикшерү уздыру аппаратурасы белән җиһазландырылырга тиеш.

## 2. Икенче һәм өченче пояслар буенча чаралар

2.1. Сулы горизонтларны пычрату ихтималлыгы өлешендә куркыныч тудыра торган барлык искергән, эшләми торган, җитешсезлекләре булган яки дөрес эксплуатацияләнми торган скважиналарны ачыклау, цементлау яки торгызу.

2.2. Яңа скважиналарны бораулау һәм яңа төзелешнең туфрак катламын бозуга бәйле эшләре дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәге белән мәҗбүри килештереп гамәлгә ашырыла.

2.3. Яраксызланган суларны җир асты су горизонтларына агызуны, каты калдыкларны җир астында урнаштыруны һәм җир асты байлыклары белән эшләр башкаруны тыю.

2.4. Ягулык-майлау материаллары, агулы химикатлар һәм минерал ашламалар складлары, сәнәгый агынтыларны туплау, шлам саклау җайланмаларын һәм җир асты суларын химик пычрату куркынычы белән аңлатыла торган башка объектларны урнаштыруны тыю.

Мондый объектларны санитар саклык зоналарының өченче поясы чикләрендә урнаштыру бары тик якланган җир асты суларыннан файдаланганда гына, сулы горизонты саклау буенча махсус чаралар үтәү шарты белән, геологик контрольлек органнары бәяләмәсен исәпкә алып бирелгән дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеге үзәгенең санитар-эпидемиология бәяләмәсе булган очракта гына рөхсәт ителә.

2.5. Файдаланыла торган сулы горизонтка турыдан-туры гидрологик бәйләнеше булган җир өсте суларын санитар саклаганда җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре нигезендә кирәкле чараларны үз вакытында башкару.

## 3. Икенче пояс буенча чаралар

2 нче бүлектә күрсәтелгән чаралардан тыш, җир асты су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарындагы икенче пояс чикләрендә түбәндәге өстәмә чаралар үтәлергә тиеш:

3.1. Рөхсәт ителми:

зиратлар, үләт базлары, урыннарда санитария шартларын яхшырту кырлары, фильтрлаштыру кырлары, тирес саклау урыннары, силос траншеялары, терлекчелек һәм кошчылык предприятиеләре һәм җир асты суларын микроб белән пычрату куркынычы тудырган башка объектларны урнаштыру;

ашламалар һәм агулы химикатлар куллану;

төп кулланудагы урманнарны кисү һәм үзгәртеп кору.

3.2. Торак пунктлар һәм башка объектлар территорияләрен санитар төзекләндерү чараларын үтәү (канализация белән тәэмин итү, су үткәрми торган ташландык су чокыры ясау, өслек суларын читкә агызуны оештыру һ.б.).